*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)
**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 40**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. [ғ] авазы кулланылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Гали
   ә) күгәрчен
   б) гөмбә
   в) вагон

2. Ирен гармониясенә буйсынган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) курчак
   ә) болан
   б) болын
   в) сөт

3. Омонимнарның төрен билгеләгез. **(2 балл)**
   *Алсу чишмәгә суга бара. – Мансур эткә таяк белән суга.*
   а) саф лексик
   ә) омоформалар
   б) омофоннар
   в) омографлар

4. Неологизмны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ноутбук
   ә) хэндмейкер
   б) алпавыт
   в) гакыл

5. Ясалма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тиен
   ә) кошчык
   б) балакай
   в) кунак

6. Җөмләдәге исемгә хас үзенчәлекне билгеләгез. **(2 балл)**

*Һәркемнең бармагы үзенә кәкре.* (Мәкаль).

а) баш килештә, тартым белән төрләнгән, берлек санда

ә) баш килештә, тартым белән төрләнмәгән, берлек санда

б) төшем килешендә, тартым белән төрләнгән, күплек санда

в) төшем килешендә, тартым белән төрләнгән, берлек санда

7. Җөмләдәге санның төркемчәсен билгеләгез. **(2 балл)**

*Шушы бер-ике көндә кайтып килербез.* (Ф. Яруллин).

а) микъдар

ә) тәртип

б) чама

в) җыю

8. Җөмләнең иясен билгеләгез. **(2 балл)**

*Куркак юлдаш дошманнан яман.* (Мәкаль).

а) куркак

ә) юлдаш

б) дошманнан

в) яман

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

Сузыкка тәмамланган иҗек –________ иҗек. [у] [ү] [о] – _____________ сузык авазлар. Тамыр һәм ясагыч кушымча – сүзнең _______________ . Башка теллләрдән кергән сүзләрне ______________ сүзләр дип атыйлар. Сыйфат ачыклап килгән исемне __________________ диләр.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. **(12 балл)**

*На реке*

*Алина и Гульназ пасли утят на реке. Утята были маленькие. Вдруг спустился к реке коршун. Он схватил одного утёнка. Девочки закричали. На крик прибежал Марат. Марат стал бросать в коршуна камни. Коршун выпустил утёнка и улетел.*

2. Сез җәйге каникулыгызны ничек уздырдыгыз? Шул хакта 7 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. **(7 балл)**